| СОВЕТ<br>МОЛВИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>МУЛЛА ИЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 октябрь 2023 ел** Мулла Иле ав. **№ _131_**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе турында" 2019 елның 01 ноябрендәге 200 номерлы Мулла Иле авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Мулла Иле авыл җирлеге Советының 2020 елның 12 ноябрендәге 15 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктату турында» 31.07.2023 № 389-ФЗ Федераль Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының " Мулла Иле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Мулла Иле авыл җирлеге Советы:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү тәртибе турында" 2019 елның 01 ноябрендәге 200 номерлы молвинский авыл җирлеге Советы карарына (Мулла Иле авыл җирлеге Советының 2020 елның 12 ноябрендәге 15 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 1.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

« Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3% шәхси торак

төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган җир кишәрлекләре;»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) , шулай ук Мулла Иле авылы, Яна урам, 3 (җирлекнең административ бинасы), Мулла Иле авылы, Үзәк урам, 17а йорты (мәдәният йорты бинасы),Зур Өтэк авылы , Яшел урам, 22а йорты (мәдәният йорты бинасы) мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Мулла Иле авыл жирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Г.Сәләхиев